КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 декабрь г.Казань № 1004

Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» 2014 ел, 6 декабрь, ПУ-1115 нче Указын алга таба тормышка ашыру, Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тормышка ашыра торган аутсорсинг шартларында транспортта балалар йөртү системасын гамәлгә кертү буенча пилот проекты нәтиҗәләрен уңай дип танырга.

2. Татарстан Республикасы министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10сына кадәр, Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе секретариатына әлеге карарда күздә тотылган чараларны тормышка ашыру турында хисап кертү;

фотога төшерү һәм видеога язып алу системаларыннан файдаланып чыгарылган административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча карарларның күчермәләрен электрон мәгълүмат таратуга тоташтыру өчен чараларны үтәүне дәвам итү.

3. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә 2018 елның 1 мартына кадәр юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу сәбәпләрен анализларга һәм 2017 елда юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерү буенча чаралар исемлеген эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

2018 елның 1 июленә кадәр автомобиль юлларының теркәү челтәрендә юл билгеләрен яңартуны тәмамларга, 2018 елның августында белем бирү оешмалары янында җәяүлеләр чыгу урыннарына юл тамгаларын кабат ясарга;

2018 елның 1 сентябренә кадәр юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерү чараларын тәмамларга, 2018 елның 10 сентябренә кадәр тиешле йомгаклау хисабын, фотоматериаллар беркетеп, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе секретариатына юлларга;

автомобиль юллары участокларын төзекләндерү яки ремонт үткәрү урыннарында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын эшләргә һәм тормышка ашырырга;

автомобиль юлларын төзекләндерү, капиталь ремонт, ремонт үткәрү, шулай ук автомобиль юлларын коралландыру кысаларында ике һәм күбрәк полосалы бер юнәлештәге юл участокларында машина юллары өстендә 5.19.1 «Җәяүлеләргә юл чыгу урыны» юл билгеләрен урнаштыруны дәвам итәргә;

каршы як хәрәкәте полосасына чыгып барлыкка килә торган юл-транспорт һәлакәтләре санын киметү өчен, шулай ук юлны чыгу өчен каралмаган урыннарда җәяүлеләрнең машиналар йөри торган өлештән чыгуын чикләү өчен барьер тибындагы металл киртәләр һәм җәяүлеләр өчен чикләүләр куюны дәвам иттерергә;

автомобиль юлларының ведомстводагы участокларында юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсен бетерү буенча чаралар күрергә, транспорт агымының туктаусыз хәрәкәтен тәэмин итәргә, шул исәптән машина юлларын транспорт чараларына узарга комачаулый торган объектлардан арындырырга.

4. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына:

2018 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе белән килештерелгән тизлекне мәҗбүри киметү чараларын урнаштыру планын тормышка ашырырга;

түбәндәгеләрне дәвам итәргә:

җир өстендәге җәяүлеләр юл чыгу урыннарына, юл чатларына якынаю урыннарында һәм потенциаль куркыныч участокларда аркылы тавышлы полосалар урнаштыруны;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларында, беренче чиратта мәгариф оешмалары, җәяүлеләр чыгу урыннары янында, автомобиль юлларының авария куркынычы булган участокларында һәм кеше күп җыела торган урыннарда ясалма яктырту урнаштыруны;

мәктәп автобусларын файдалану мониторингы һәм аларның файдалана алырлык булуы, тизлек режимын саклавы турында мәгълүматны мәнфәгатьле министрлыкларга һәм ведомстволарга тапшыру;

түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына 2018 елга юл эшләре программасы нигезендә мәктәп автобуслары маршрутлары уза торган гомуми файдаланудагы автомобиль юллары участокларының техник һәм эксплуатация сыйфатламаларын күтәрү өчен чаралар үтәүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары белән 2018 елның 15 мартына кадәр муниципаль юл фондлары акчасының файдаланылмаган өлешен 2018 елда юл хәрәкәте иминлеген күтәрү буенча беренче чираттагы чараларны башкаруга, юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын һәм проектларын эшләүгә юнәлдерү турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән килештергән тәкъдимнәрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы һәм Транспорт өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең дәүләт автомобиль юлы күзәтчелеге Урта Идел төбәкара идарәсе белән ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге кысаларында:

автобусларда пассажирларны законсыз йөртү фактларына юл куймау буенча чараларны даими нигездә үткәрергә;

пассажирларны санкцияләнмәгән җибәрү урыннарында криминоген хәлне кисәтүгә йөз тоткан чаралар үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

мәктәп автобусларында балаларны оешкан рәвештә йөртү, шул исәптән «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган тахограф һәм борттагы навигация җайланмалары эшләве кагыйдәләрен саклауны тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә;

мәгариф оешмаларында соңгы дәресләрдә көн саен «иминлек минутлары» үткәрү мәсьәләсе өстендә эшләргә, аның кысаларында балаларга, табигать шартларына һәм урам челтәре үзенчәлекләренә игътибар итеп, Юл хәрәкәте кагыйдәләрен саклау кирәклеге турында искә төшерергә;

түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы «Тереклек эшчәнлеге иминлеге фәнни үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән укытучыларны һәм тәрбиячеләрне «Мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балаларны юлларда үзеңне сак тоту кагыйдәләренә өйрәтүнең заманча белем бирү технологияләре» программасы буенча укытуны дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына мәктәп автобусларын тикшерүдә тотуның техник чаралары, йөртүчеләр карталары, калибровкалау таблицалары һәм тахографларны калибровкалау сертификатлары белән тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән:

түбәндәгеләрне оештырырга:

җәйге каникуллар чорында «Дзержинец» балалар сәламәтләндерү лагеры базасында яшь хәрәкәт инспекторлары конкурсының район этабы призерларының профильле сменасын;

пассажирларның үзләрен куркынычсыз тоту күнекмәләрен ныгыту буенча мәктәп автобуслары салоннарында укучылар белән даими инструктажлар үткәрү, шулай ук транспорт чаралары салоннарында тематик күрсәтмә мәгълүмат урнаштыру;

мәгариф оешмалары укучыларының караңгы вакытта киемнәрендә яктылыкны кайтару элементларын йөртүне тикшерүдә тоту;

мәгариф оешмалары сайтының баш битендә (www.edu.tatar.ru) «Юл иминлеге» ссылкасын булдыру, анда юл хәрәкәте иминлеге турында актуаль мәгълүмат, ата-аналар һәм укучылар өчен юл иминлеге паспортлары һәм укучының куркынычсыз маршруты схемасы урнаштырыла, профилактик мәгълүмат яңартылып бару һәм аның эчтәлеге тикшерүдә тотыла;

балаларда һәм яшүсмерләрдә юл хәрәкәтендә имин катнашу күнекмәләрен үстерү максатында җәяүле йөреп кайтулар, алар барышында укучыларның игътибарын мәгариф оешмасына имин барып җитү маршрутында булган урам-юл объектларына җәлеп итергә;

яшь хәрәкәт инспекторлары отрядлары эшчәнлегенә оештыру ярдәме күрсәтү.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хатын-кызлар консультацияләре һәм республиканың медицина оешмалары балалар поликлиникалары базасында юл хәрәкәте иминлеге турында лекцияләр үткәрү өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына шартлар тудырырга.

7. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә 2018 елның 1 апреленә кадәр мәктәп автобусларын мониторинглау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бер тапкыр смартфоннар сатып алу турында тәкъдимнәр эшләргә һәм Татарстан Республикасы Президенты каравына кертергә.

8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына:

яшьләр оешмаларын һәм берләшмәләрен юл-транспортта имгәнүләрне кисәтү буенча эшкә җәлеп итүне оештырырга, шул исәптән пропаганда чаралары һәм махсуслашкан акцияләр һәм семинарлар кысаларында;

мәктәп автобусларында балаларны оешкан рәвештә йөртү, шул исәптән «ГЛОНАСС+112» бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтырылган тахограф һәм борттагы навигация җайланмалары эшләве кагыйдәләрен саклауны тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән берлектә балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре директорларын укучыларны йөртергә транспорт хезмәте күрсәтүләрне сатып алуларны (аутсорсинг) гамәлгә ашыру буенча укулар оештырырга;

аутсорсинг шартларында балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләренә транспорт хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашырырга (2016 –2017 елда чыккан автобусларны файдаланудан тыш).

9. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары белән берлектә мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенә аутсорсинг шартларында транспортта йөртүләрне кертергә, нәтиҗәләре турында 2018 елның 1 июленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат бирергә.

10. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

ярты елга кимендә бер тапкыр Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарын җәлеп итеп, юл-транспорт һәлакәтләренә җавап кайтару буенча махсус тактик укулар үткәрергә;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә гомуми белем бирү оешмаларында «Тормыш иминлеге өчен юлларда иминлек» темасына тереклек эшчәнлеге иминлеге нигезләре буенча дәрес үткәрергә;

оператив җавап кайтару һәм юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәләрен бетерүгә җәлеп ителә торган көчләрне һәм чараларны үз вакытында әзер булуы максатларында Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу оператив фаразын көн саен мәнфәгатьле министрлыкларга һәм ведомстволарга җиткерүне оештырырга;

Татарстан Республикасы янгыннан коткару бүлекчәләрен техниканың заманча үрнәкләре, авария-коткару кораллары белән тәэмин итүне дәвам итәргә.

11. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына яшүсмерләр һәм балалар өс киемнәре һәм аяк киемнәре җитештерүчеләргә яктылык кайтару элементларын куллануны киңәш итәргә.

12. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә:

2018 елның 1 июленә кадәр «Лада Ларгус» автомобильләре базасында Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны фиксацияләүнең «Робот» автоматлаштырылган мобиль комплексларын гамәлгә кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә 2018 елның 1 сентябренә кадәр федераль әһәмияттәге автомобиль юлларының барлык озынлыгында билгеләнгән хәрәкәт тизлеген арттыруны тикшерүдә тоту зоналары санын арттыру буенча чаралар күрергә;

төбәк әһәмиятендәге һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында зур габаритлы һәм авыр транспорт чаралары хәрәкәтенең автоматлаштырылган йөк һәм габарит контроле системаларын уңайлаштыру һәм кулланышка кертү буенча чаралар күрергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» ярдәмче программасы чараларын финанслашуын тикшерүдә тотуны көчәйтергә.

13. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән

берлектә массакүләм мәгълүмат чараларында даими нигездә юл хәрәкәте иминлеге буенча социаль реклама урнаштыруны оештырырга, шул исәптән:

тәүлекнең караңгы вакытында һәм күз күреме начар булганда җәяүлеләр тарафыннан, шулай ук транспорт чараларын йөртүчеләр трассада автомобильдән чыкканда яктылык кайтару элементларын куллану турында;

юл-транспорт һәлакәтләрен полиция хезмәткәрләре катнашыннан башка рәсмиләштерүне популярлаштыру турында;

автомобильләрнең тиешле краш-тестларын күрсәтеп, транспорт чарасында хәрәкәт вакытында куркынычсызлык ременьнәреннән файдалану кирәклеге турында;

исерек хәлдә транспорт чарасы белән идарә итү фактлары һәм мондый фактларның фаҗигалы нәтиҗәләре турында.

13. Тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына:

транспорт чарасы белән идарә итү хокукыннан мәхрүм ителгәннән соң машина йөртү таныклыгын бирмәгән йөртүчеләрдән аларны алу буенча чараларны дәвам итәргә;

автомобиль юлларын төзекләндерү, капиталь ремонт һәм ремонт ясау буенча эшләр башкару урыннарында аварияләрне профилактикалау чаралары үткәрүне оештыру;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия утырышларын әзерләүдә һәм уздыруда катнашу;

түбәндәгеләр белән берлектә:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе белән 2018 елның 1 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе хезмәткәрләрен «Беренчел ярдәм күрсәтү» курсы буенча укыту үткәрү мөмкинлеген карап тикшерергә;

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Куйбышев тимер юлының Идел-Кама территориаль транспорт төбәге буенча территориаль идарәсе һәм «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Горький тимер юлының Казан территориаль идарәсе белән Тимер юл аркылы чыгу урыннарында юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуларны фото- һәм видеофиксацияләү җайланмаларын урнаштырырга һәм файдалануга кертергә;

Федераль суд приставларының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.25 статьясының 1 өлешендә, 12.8, 12.26 статьяларда каралган административ эшләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча суд органнары салган административ штрафларны түләтү һәм бурычлыларның транспорт чараларына арест салу буенча эшчәнлекне активлаштырырга;

суд карарларын мәҗбүри эшләр рәвешендә тиешле үтәлешен тикшерүдә тотуны оештырырга;

«Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» федераль казна учреждениесенә җир өстендәге җәяүлеләр юл

чыгу урыннарына, юл чатларына якынаю урыннарында һәм потенциаль куркыныч участокларда аркылы тавышлы полосалар һәм транспорт чаралары әйләнеп каплануын булдырмау максатларында машина юлы кырые буйлап буйга тавышлы полосалар урнаштыруны дәвам итәргә;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты, Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты һәм Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчеләренә түбәндәгеләр буенча чаралар күрергә:

муниципаль пассажир транспортында һәлакәтләр куркынычын профилактикалау, шул исәптән пассажирлар иминлеген тәэмин итү;

пассажирлар йөртүне даими тормышка ашыручы йөртүчеләрнең керемнәре план күрсәткечләрен үтәүгә бәйле булуга юл куймау;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетларына:

2018 елның 15 гыйнварына кадәр «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесенә юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программаларны, алга таба квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5сенә кадәр – әлеге максатчан программаларны тормышка ашыру барышы турында мәгълүматны тапшырырга;

2018 елның 1 мартына кадәр эчке эшләр органнарының территориаль бүлекчәләре белән берлектә юл-транспорт вакыйгаларының барлыкка килү сәбәпләрен анализларга һәм 2017 елда транспорт вакыйгалары күп булган урыннарны, шулай ук автомобиль юлларының аварияләр ихтимал булган участокларын бетерү чаралары исемлеген Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте комиссиясе секретариатына тапшырырга;

2018 елның 1 апреленә кадәр уртак кулланудагы автомобиль юллары участокларында, беренче чиратта мәгариф оешмалары, җәяүлеләр чыгу урыннары янында, автомобиль юлларының һәлакәт куркынычы зур булган участокларында һәм халык күп җыела торган урыннарда ясалма яктыртуны җайга салу буенча план эшләргә;

2018 елның 1 июленә кадәр:

генераль үстерү планнары нигезендә җирлекләр һәм шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшләргә, юл хәрәкәтен оештыру проектларын эшләүне дәвам итәргә һәм 2018 елның 1 декабренә кадәр юл хәрәкәтен оештыруның комплекслы схемаларын эшләүне тәмамларга;

автомобиль юлларының терәк челтәрендә юл сызыгын яңартуны тәмамларга, 2018 елның августында мәгариф оешмалары янында җәяүлеләр чыгу урыннарына юл тамгаларын кабат сызарга;

мәгариф оешмаларының юл иминлеге паспортларын билгеләнгән нормативларга туры китерергә;

2018 елның 1 сентябренә кадәр:

җәяүлеләр хәрәкәте өчен, беренче чиратта мәгариф оешмалары янында, илкүләм стандартлар таләпләре нигезендә, куркынычсыз шартлар тудыру буенча, шул исәптән урам-юл челтәрен җайга салуны мәгариф оешмаларының юл иминлеге паспортларына туры килүе өчен өстәмә чаралар күрергә;

юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннарны бетерү чараларын тәмамларга, 2018 елның 10 сентябренә кадәр тиешле йомгаклау хисабын, фотоматериаллар беркетеп, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе секретариатына юлларга;

2018 елның 10 декабренә кадәр 2019 елда муниципаль әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тотуга муниципаль контрактлар төзергә;

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләрне гомуми белем бирү оешмаларында укырга әзерләү кысаларында беренче сыйныф укучыларын яктылык кайтаручы элементлар белән тәэмин итәргә, 2019 елның 1 гыйнварына кадәр аларны яңа ел бүләкләренә кертүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә урам-юл челтәрен карап тотуга, юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын карап тотуны, юлдагы чокырларга ремонт үткәрү һәм юл сызыгын сызуны кертеп, озак вакытлы муниципаль контрактлар төзү мөмкинлеген (расланган бюджет йөкләмәләре лимитларының гамәлдә булу вакытын исәпкә алып) карап тикшерергә;

бюджетларда юл хәрәкәте иминлеген күтәрү буенча муниципаль максатчан программалар чараларын тормышка ашыруга чыгымнарны (җәяүлеләр юл чыгу урыннарын төзекләндерү, җәяүлеләр һәм барьер киртәләр урнаштыру, юл сызыгын сызу, автомобиль юлларны кышын карап тоту, юлдагы чокырларга ремонт, юл хәрәкәтен оештыруның техник чараларын карап тоту, яктылык кайтару элементларын сатып алу һ.б.) күздә тотарга;

бер юнәлештә ике яки күбрәк полосалы юл участокларында автомобиль юлы өстендә 5.19.1 «Җәяүлеләр юл чыгу урыны» юл билгеләрен урнаштыруны дәвам итү;

җайга салынмый торган җәяүлеләр чыгу урыннарын уңайландыру буенча чаралар үткәргәндә өстәмә светодиод яктырту һәм эчке светодиод яктырту белән тартма рәвешендә башкарылган (электр челтәрләренә яки стационар тәэмин итү чыганакларына тоташтыру мөмкинлеге булганда) 5.19.1 – 5.19.2 «Җәяүлеләр юл чыгу урыны» юл билгеләрен урнаштыруны күздә тотарга;

санкцияләнмәгән пассажирлар җибәрү урыннарын бетерү буенча тулы чаралар күрергә;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча муниципаль комиссия эше кысаларында халыкта яктылык кайтару элементларын куллануны популярлаштыру мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә;

күпфатирлы йортлар подъездларында һәм лифтларында мәгълүмат такталарына юл хәрәкәте иминлеге турында социаль реклама урнаштыру мәсьәләсен җентекләп өйрәнергә;

автомобиль юллары участокларын төзекләндерү һәм ремонтлау урыннарында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын тормышка ашырырга;

каршыга хәрәкәт полосасына чыгу нәтиҗәсендә юл-транспорт фаҗигалары санын киметү өчен, шулай ук җәяүлеләр автомобильләр йөри торган юлга чыгу өчен каралмаган урыннарда җәяүлеләрнең автомобильләр йөри торган юлга чыгуын чикләү өчен барьер төрендәге металл киртәләр һәм җәяүлеләр өчен киртәләрне куюны дәвам итәргә;

автомобиль юлларының ведомстводагы участокларында юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсен бетерү буенча чаралар күрергә, транспорт агымының туктаусыз хәрәкәтен тәэмин итәргә, шул исәптән машина юлларын транспорт чараларына узарга комачаулый торган объектлардан арындырырга;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының территориаль бүлекчәләре белән берлектә юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булганнарны сәламәтлек саклау учреждениеләренә транспортлау буенча үзара багланышларны оештырырга;

юл сервисы объектларының юл хәрәкәте куркынычсызлыгы өлкәсендәге законнар таләпләренә туры килмәве билгеле булганда объект хуҗаларын бозуларны бетерергә мәҗбүр итәргә, таләп үтәлмәгән очракта мәгълүматны прокуратура органнарына җибәрергә.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар турында» 2016 ел, 27 декабрь, 1011 нче һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре санын азайту һәм алар сала торган зыяннар авырлыгын киметү буенча өстәмә чаралар хакында» 2016 ел, 27 декабрь, 1011нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 16 март, 149 нчы карарлары үз көчен югалткан дип санарга.

15. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Административ һәм хокук саклау органнары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин